

Аксёново – Мордовиянен Ләмберә районындагы татар авылы. Саранскидан 10 км тоньяк-кончыгышка таба Саранск – Самара трассасы буенча Елшанка елгасы буенда урнашкан. 2019 елда 350 еллык Юбилей бәйрәмен Сабантуй конендә vткәрде.
Анын исеме-антропоним, диелә Википедиядә: «1669-1670 елларда Атемар унлыгында» Сюнбайко Аксёнов Саранск оязендә рейтар булып хезмәт иткән, биредә жире булган.
 Аксёновлар зур, чәчәк атучы авылга нигез салучылар булып чыга. Тагы бер версия буенча – ак су сvзләреннән авыл исеме барлыкка килгән. «Арсланова (Байметова) Астма Сафиулла кызы (1903 елгы) хикәяләре буенча, Аксёново – ак су, дигәнне анлата, дип язылган «Академик сvзлек»тә. Тагы шундый мәгълумат та игътибарга лаек. Авылдагы риваять буенча, Әхсән бабай бу авылга нигез салучы, дип тә сойли Аксёново картлары.



«Пенза губерниясынын торак урыннары исемлегендә» (1869 ел мәгълvматлары буенча) Аксёново – Саранск оязенен 83 ишегалдыльı авыл. 1917 елга бирадә ишегаллары саны 213кә кадәр арткан. Авыл общинасы 1306 жанны берләштергән. 1930 нчы еллар башында Чапаев исемендәге совхоз оештырыла. Авылнын заманча инфраструктурасында – урта мәктәп, клуб, китапханә, кибетләр, медпункт эшли.
Аксёново авыл жирлеге территориясендә беренче колхозлар 1930 елда оеша. Болар – «Кызыл дулкын» һәм «Кызыл юл». Бу хужалыклар «Алга»  колхозына берләшә һәм торле елларда Хасян Абдрашитов, Калимулла Байметов, Хаким Мишаев, Закарья Бикмаев, Кадир Ахметов, Билял Батряков житәклиләр. 1973 елда Ләмберә комсомол райкомынын беренче секретаре Шагидулла Сюбаевка Аксёново авылында авыл хужалыгы предприятиесен житәкләргә тәкъдим ителә. Озакламый «Чапаев» исемендәге берләштерелгән хужалык барлыкка килә һәм бу совхоз житештерvен дә кинәйтә: яна тозелгән дvрт ишегалдында 410 баш могезле эре терлек (280 баш сыер) асрый башлыйлар. Кыска гына вакыт эчендә биредә остаханә, административ бина, спорт залы булган клуб, 140 урынга исәпләнгән балалар бакчасы тозелә. Эшчеләр саны 120 кешегә кадәр арта. Совхозны vстерv юлында ат vрчетv һәм суган vстерv – алга таба адым була:

хужалык 200 мен сумга кадәр чиста табыш ала башлый. Совхоз акчасына 60 фатирлы ике йорт һәм мен тонна бәрәнге саклау урыны, бозаулар белән сыерлар абзарлары тозелә, Аксёново – Татар Тавла – Атемар юлын тозекләндерәләр.



Югары житештерv кvрсәткечләре очен кvп кенә хужалык хезмәтчәннәре орден һәм медальләр белән бvләкләнә. Алар арасында сыер савучы, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Хәсибә Синятулла кызы Янгаева, Почет Билгесе ордены кавалеры Мянсура Хәмзә кызы Абдуллова бар.
Заманалар алга атлаган саен, Аксёновода да vзгәрешләр арта. 2002 елда Рафик Айяс улы Фетхуллов житәкчелегендәге «Юлдаш» крестьян-фермер хужалыгы уңышлары турында башка регионнар да хәбәрдар. Бу предприятие кvп кенә аксёноволыларны эш урыннары белән тәэмин итә, авыл остендә барлыкка килгән мәсьәләләрне чишәргә, бәйрәмнәрне оештырырга да матди яктан ярдәм итә.
- 1600дән артык кеше яшәгән авылыбыз тырыш кешеләргә бай. Бvгенге кондә КФХ «Юлдаш» хужалыгы уңышлы эшләп килә; ярдәмен тоеп яшибез. Мәсәлән, торле килеп чыккан проблемаларны чишәргә, милли мәдәниятны vстерергә ярдәме очен КФХ «Юлдаш» житәкчесе Рафик Айяс улы Фетхулловка халкыбыз рәхмәтле. Тагы ит vстерv һәм сату эшләре белән шогыльләнгән утызлап шәхси эшмәкәребез бар. Оч йозләп эре могезле хайван vстерәләр, итен-сотен саталар. Жиһазланган мал-туар бугазлау урыннарыбыз эшли. Маллар vрчеткәндә килеп чыккан проблемалар булгалый, мәсәлән, навозын кая ташырга дигәне. Кечкенә, әмма хәл итvне таләп итә, – дигән мәгълуматны авыл администрациясе житәкчесе Айса Жәфәр улы Юсупов житкергән иде.
Авылда рухи традицияләрне, туган телне саклауга бик сак карыйлар. Шунысы куанычлы, Аксёново гаиләләрендә татарча сойләшәләр. Урамнарда, учреждениеләрдә татар сvзе даими ишетелеп тора, әнисенен соте белән сеңдерелгән шундый матур авазлары белән ишетелә. Бу сакраль кыйммәтләрне саклап калуга олкәннәрне хормәт итvгә һәм хормәтләvгә, хезмәт союченлеккә һәм vзара ярдәмгә нигезләнгән гаилә һәм мәктәп (vткән 2021 елда ике катлы яна урта мәктәп эшли башлады: татар теле һәм әдәбияты ойрәнелә), шулай ук соңгы дистә елларда vз рухи чыганакларын актив торгызу процессы барган жәмгыять ярдәм итә.
Борынгы заманнардагы кебек vк, авыл мәчетләре дә рухи һәм рухи чистарыну сагында тора. Инкыйлабка кадәр Аксёновода оч мәчет була. Аларда оч башлангыч мәктәп эшли, документлар да татарча язылган. Хәзер дә Аксёновода оч мәчет эшли; аларнын ишекләре дин тотучылар очен һәрвакыт ачык. Менә шундый ул Аксёново дигән хезмәт яратучы татарлар авылы.

**Наилә НАСЫРОВА**